Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**28 октябрь 2022 ел** **№ 1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 28 октябрендә 11 сәгать 00 минутта, 2022 елның 28 октябрендә 12 сәгать 00 минутта булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә житкән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы":

- янгын сүндерү машинасын тоту, янгын автомашинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү;
- үләнне чабып алу (хезмәт шартнамәсе буенча түләү);
- МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, юлларга хезмәт күрсәтү, кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май, запас частьләр сатып алу, хезмәт шартнамәсе буенча түләү);
- Бөек Ватан сугышы елларында катнашучы якташлар хөрмәтенә куелган һәйкәлне агымдагы ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәт шартнамәсе буенча түләү);
- Күләгәш авылында Яшьләр, Казан урамнары, Спорт тыкрыгы юллары өчен вак таш сатып алу һәм алар белән юлларны каплау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 210 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 112 кеше, бу – 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 112 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл жирлеге» Күләгәшторак пункты территориясендә, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлардан (80 яшькә житкәннәр), көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан һәм шәхесләрдән тыш ирektән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. янгын сүндерү машинасын тоту, янгын автомашинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү;

2. үләнне чабып алу (хезмәт шартнамәсе буенча түләү).

3. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, юлларга хезмәт күрсәтү, кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май, запас частьләр сатып алу, хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

4. Бөек Ватан сугышы елларында катнашучы якташлар хөрмәтенә куелган һәйкәлне агымдагы ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

5. Күләгәш авылында Яшьләр, Казан урамнары, Спорт тыкрыгы юллары өчен вак таш сатып алу һәм алар белән юллары каплау

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Ю.Н. Васильев

Совет Кулегашского сельского поселения
Күләгәш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002639